СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 нчы июнь 2022 ел № 20-72

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының санын һәм урнашу урыннарын расларга, кушымта нигезендә.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 22.10.2005 №1-6 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatrstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В.М.Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге
Советының 2022 елның 29
июненнән 20-72 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары

| Урнашу урыны | Норматив-хокукый акт урнаштыру өчен форма атамасы | Саны, шт. |
|---|---|---|
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Совет ур, 74 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Завод ур., 3 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |